ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.11.2024 ел Баулы шәһәре №163

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 116 номерлы карары белән расланган, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2022 елның 13 маендагы 82 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) өстәмә кертү турында

«Эскроу счетларыннан файдаланып, төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 22 июлендәге 187-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 116 номерлы карары белән расланган, индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2022 елның 13 маендагы 82 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге өстәмә кертергә:

2 бүлектә «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартлары»:

2.5.1.пунктын 10) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«10) эскроу счетыннан файдаланып, төзелеш подряды шартнамәсе турында белешмәләр, мондый шартнамә нигезендә индивидуаль торак төзелеше объектын төзү эшләрен башкаручы зат турында белешмәләрне дә кертеп («Эскроу счетларыннан файдаланып, төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында» Федераль законы нигезендә, индивидуаль торак төзелеше объектын төзегәндә );».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров